| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 15 декабрь, 2016 ел | № 13/11 |

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча Шәһәр Советының аерым карарлары турында

Татарстан Республикасының 2013 елның 25 июнендәге «Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексы» 50-ЗРТ санлы Законы, Яр Чаллы шәһәре Уставының 28, 48, 49 маддәләре нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2008 елның 18 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 31/13 санлы Карарына (Шәһәр Советының 2009 елның 9 апрелендәге 40/23, 2012 елның 20 сентябрендәге 21/11, 2013 елның 29 августындагы 26/15, 2015 елның 22 октябрендәге 2/19 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 пунктта «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» сүзләрен «Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексы» сүзләренә алыштырыга;

2) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Муниципаль хезмәт вазифасын биләү өчен, һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт яки белгечлек, хәзерлек юнәлеше буенча эш стажына, хезмәт вазифаларын башкару өчен кирәк булган белем һәм күнекмәләргә, шулай ук эш бирүче вәкиленең тиешле карары булганда – белгечлеккә, хәзерлек юнәлешенә куелган квалификация таләпләренә туры килү сорала.»;

3) түбәндәге эчтәлектәге 7.1 пунктын өстәргә:

«7.1. Муниципаль хезмәт вазифасын биләү өчен түбәндәге квалификация таләпләре куела:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә:

муниципаль хезмәтнең югары, баш һәм әйдәүче вазифалары өчен югары белем булу;

муниципаль хезмәтнең өлкән һәм кече вазифалары өчен югары белем яки урта һөнәри белем булу;

2) муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек, хәзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазифалары буенча – муниципаль хезмәт стажы ике елдан да ким түгел яки белгечлек, хәзерлек юнәлеше буенча эш стажы биш елдан да ким түгел;

муниципаль хезмәтнең баш вазифалары буенча – муниципаль хезмәт стажы бер елдан да ким түгел яки белгечлек, хәзерлек юнәлеше буенча эш стажы ике елдан да ким түгел;

муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазифалары буенча – муниципаль хезмәт стажы бер елдан да ким түгел яки белгечлек, хәзерлек юнәлеше буенча эш стажы ике елдан да ким түгел.

Муниципаль хезмәтнең өлкән һәм кече вазифалары буенча муниципаль хезмәт стажына, белгечлек, хәзерлек юнәлеше буенча эш стажына квалификация таләпләре куелмый.»;

4) түбәндәге эчтәлектәге 7.2 пунктын өстәргә:

«7.2. Муниципаль хезмәтнең тиешле вазифасы буенча хезмәт вазифаларына Татарстан Республикасының 2015 елның 25 апрелендәге «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 33-ЗРТ санлы Законы нигезендә җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашу кергән очракта, муниципаль хезмәтнең өлкән һәм кече вазифалары буенча һөнәри белем дәрәҗәсенә (урта гомуми белем булганда) 2019 елның 1 январенә кадәр квалификация таләпләре куелмый.»;

5) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Муниципаль хезмәт вазифасын биләү өчен кирәкле һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт яки белгечлек, хәзерлек юнәлеше буенча эш стажына квалификация таләпләре муниципаль хезмәт вазифаларын биләү өчен типлаштырылган квалификация таләпләре нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

Хезмәт вазифаларын башкару өчен кирәк булган белем һәм күнекмәләргә квалификация таләпләре муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә бәйле рәвештә, вазифаи инструкциясе нигезендә билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазифаи инструкциясе белән шулай ук белгечлеккә, хәзерлек юнәлешенә квалификация таләпләре куелырга мөмкин.

Мәгълүмати-коммуникацион технологияләр өлкәсендә хезмәт вазифаларын башкару өчен кирәкле һөнәри белем һәм күнекмәләргә квалификация таләпләре җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары белән билгеләнә.»;

6) Муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү турында нигезнамәгә кушымтаның 3 пунктында «белгечлек» сүзеннән соң «, хәзерлек юнәлеше» сүзләрен өстәргә.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының 2010 елның 15 июлендәге «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт вазифаларын үтәү өчен кирәкле булган муниципаль хезмәтнең вазифаларын биләүгә

квалификация таләпләрен раслау турында» 52/6 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2010 елның 21 июлендәге 137-138 саннарында басылган);

2) Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге «Шәһәр Советының Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 21/11 санлы Карарының 2 пункты;

3) Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы «Шәһәр Советының Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 26/15 санлы Карарының 2 пункты;

4) Шәһәр Советының 2015 елның 22 октябрендәге «Шәһәр Советының Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2/19 санлы Карарының 2 пункты

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев